| Республика Татарстан | | Татарстан Республикасы |
|---|---|---|
| Исполнительный комитет<br>Менделеевского<br>муниципального района | | Менделеевск муниципаль<br>районы<br>башкарма комитеты |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.05.2024 Менделеевск ш. № 279

Менделеевск шәһәре территориясендә
җәмәгать транспортының тукталыш пунктлары реестры
турында нигезләмәне һәм Менделеевск шәһәре территориясендә
җәмәгать транспортының тукталыш пунктлары реестрын раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 мартындагы 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә җәмәгать транспорты эшен җайга салу, шулай ук җәмәгать транспорты тукталышы пунктларын урнаштыру урыннарын исәпкә алуны оештыру максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1.Менделеевск шәһәре территориясендә җәмәгать транспортының тукталыш пунктлары реестры турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Менделеевск шәһәре территориясендә җәмәгать транспортының тукталыш пунктлары реестрын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Менделеевск шәһәре территориясендә җәмәгать транспортының тукталыш пунктлары реестрында булган белешмәләрне актуальләштерү һәм җәмәгать транспортын туктату урыннарын норматив хәлгә китерү максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте һәм шәһәр хуҗалыгы бүлегенә 2024 елның 1 июненә кадәр тукталыш пунктларының географик координаталарын билгеләү буенча эшләрне гамәлгә ашырырга, аннары алынган белешмәләрне тукталыш пунктлары реестрына кертергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Норматив документлар» бүлегендә урнаштырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында http//pravo.tatarstan.ru бастырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары С.В. Метальниковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров

Килештерелде
Шәһәр хуҗалыгы буенча
җитәкче урынбасары С.В. Метальников

Юридик бүлек башлыгы Е.С. Царева

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 16 маендагы 279 номерлы

карарына
1 кушымта

Менделеевск шәһәре территориясендә
җәмәгать транспортының тукталыш пунктлары реестры турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәре территориясендә җәмәгать транспортының тукталыш пунктлары реестры (алга таба - тукталышлар реестры) юридик һәм физик затларның рәсми документларында тукталыш исемнәрен регламентлаштырылган һәм бертөрле куллану максатларында эшләнгән.

1.2. Тукталышлар реестры Менделеевск шәһәренең җәмәгать транспорты муниципаль челтәрендә урнашкан җәмәгать транспорты өчен тукталышларны үз эченә ала. Исемнәре Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән бирелгән.

1.3. Әлеге Нигезләмә җәмәгать транспорты тукталышларының исемнәрен бирү (үзгәртү) тәртибен, шулай ук тукталышлар реестрын булдыру һәм алып бару тәртибен билгели.

2. Тукталышлар реестрын төзү һәм алып бару

2.1. Тукталышлар реестрын формалаштыруны һәм алып баруны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте һәм шәһәр хуҗалыгы бүлеге башкара. Җәмәгать транспорты тукталышының исеме Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән тиешле исем бирелгән вакыттан алып биш эш көне эчендә тукталышлар реестрына кертелә.

2.2. Тукталышлар реестрын алып бару яңа ачылган тукталышларның исемнәре реестрына кертү, гамәлдәге тукталышларның исемнәрен үзгәртү һәм ябык тукталышларның исемнәре реестрыннан тыш башкарыла.

2.3. Тукталышлар реестры кәгазь һәм электрон чыганакларда алып барыла. Электрон чыганаклардагы язмаларга кәгазь чыганаклардагы язмалар туры килмәгәндә, өстенлек кәгазь чыганакларда языла.

3. Җәмәгать транспорты тукталышлары исемнәрен бирү (үзгәртү) тәртибе

3.1. Җәмәгать транспорты тукталышлары атамаларын бирү (үзгәртү) буенча тәкъдимнәр физик һәм юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетына кертелә.

3.2. Карарга тапшырыла торган документлар исемлеге:

- физик яисә юридик затларның үтенечнамәсе (гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның почта адресы һәм телефон номеры яисә оешманың исеме һәм адресы, контактлы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм телефон номеры);

-тиешле территориянең карта-схемасы (график схема);

-кертә торган тәкъдимне нигезләүне үз эченә алган аңлатма.

3.3. Реестрга үзгәрешләр кертү кирәк булганда, сораштырулар, шәһәр халкы җыелышлары, гамәлдәге норматив хокукый актлар нигезендә гавами тыңлаулар уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

3.4. Тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте һәм шәһәр хуҗалыгы бүлеге тарафыннан карала, ул тукталышлар реестрына үзгәрешләр кертүнең максатчанлыгы турында карар чыгара.

3.5. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте һәм шәһәр хуҗалыгы бүлеге мөстәкыйль рәвештә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә тукталышлар исемнәрен бирү, үзгәртү, өстәү буенча тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

3.6. Җәмәгать транспорты тукталышлары исемнәрен бирү (үзгәртү) Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының карары нигезендә гамәлгә ашырыла һәм Җәмәгать транспорты тукталышлары реестрына кертелә.

4. Тукталышлар реестры эчтәлеге

Тукталышлар реестры таблица формасында рәсмиләштерелә һәм түбәндәге бүлекләрне үз эченә ала:

- тукталышлар реестрында тукталышның тәртип номеры;
- тукталыш павильоны урнашу адресы;
- тукталыш павильоны исеме;
- татар телендәге тукталыш павильоны исеме.

5.Тукталышлар реестрындагы белешмәләрнең һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү

5.1. Тукталышлар реестрында булган мәгълүматлар ачык һәм һәркем файдалана алырлык булып тора.

5.2. Тукталышлар реестры Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http//pravo.tatarstan.ru басылып чыгарга һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru урнаштырылырга тиеш.

Татарстан Республикасы<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Башкарма комитетының<br>2024 елның 16 маендагы 279 номерлы<br>карарына

2 кушымта

# Менделеевск шәһәре территориясендә җәмәгать транспортының тукталыш пунктлары реестры

| № т/б | **Тукталыш павильонының урнашу адресы** | **Тукталыш павильоны аталышы** | **Тукталыш павильоны исеме (тат. телдә)** | **Искәрмә** |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Тукай урамы («Аммоний» скверы янында) | «Аммоний» скверы тукталышы | «Аммоний» скверы тукталышы | 1 павильон |
| 2 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Габдулла Тукай урамы (Менделеевск үзәне"нә якынрак), | «Тукай» тукталышы | «Тукай» тукталышы | 1 павильон |
| 3 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Химиклар урамы («Чаллы икмәге» кибете янында) | "Химиклар" тукталышы | "Химиклар" тукталышы | Бер-берсенә каршы 2 павильон |
| 4 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Химиков урамы 1Г (вокзал янында) | "Автостанция" тукталышы | "Автостанция" тукталышы | 1 павильон |
| 5 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Юбилей урамы ("Мең төрле вак-төяк"кибете» һәм Дан аллеясы янында) | "Дан аллеясы" тукталышы | "Дан аллеясы" тукталышы | 1 павильон |
| 6 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Профсоюз урамы («Химик» спорт комплексы янында) | "Химик спорт комплексы" тукталышы | "Химик спорт комплексы" тукталышы | Бер-берсенә каршы 2 павильон |
| 7 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Совет урамы ("Химик" спорт комплексы янында) | "Химик спорт комплексы" тукталышы | "Химик спорт комплексы" тукталышы | 1 павильон |
| 8 | Күпердән Әгерҗе ягына чыгу ( «Яшлек»ЯҮ каршында | «Яшьләр үзәге» тукталышы | «Яшьләр үзәге» тукталышы | 1 павильон |
| 9 | Күпердән Яр Чаллы ягына чыгу | «Яшьләр үзәге» тукталышы | «Яшьләр үзәге» тукталышы | 1 павильон |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 10 | Яр Чаллы ягына ("Табыш" кибете каршында (Находка)) | «АГЗС» тукталышы | Автогаз ягулык салу станциясе (АГЯСС) тукталышы | 1 павильон |
| 11 | Яр Чаллы ягына (Кояшлы урамы каршында) | "Кояшлы урам" тукталышы | "Кояшлы урам" тукталышы | Бер-берсенә каршы 2 павильон |
| 12 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Елга урамы («Яшлек» ЯҮ янында) | "Елга" тукталышы | "Елга" тукталышы | Бер-берсенә каршы 2 павильон |
| 13 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Яр буе урамы (кибет янында) | «Яр буе» тукталышы | «Яр буе» тукталышы | 1 павильон |
| 14 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Яр буе урамы (Чиркәү янында) | "Шәһәр пляжы" тукталышы | "Шәһәр пляжы" тукталышы | Бер-берсенә каршы 2 павильон |
| 15 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Фомин урамы (КФҮ янында) | "Башкарма комитет" тукталышы | "Башкарма комитет" тукталышы | 1 павильон |
| 16 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Фомин урамы (Олимп кибете янында) | "Фомин урамы" тукталышы | "Фомин урамы" тукталышы | Бер-берсенә каршы 2 павильон |
| 17 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Фомин урамы (ЭЭБ, ЮХИДИ, 4 мәктәп янында). | "Батырлык мәктәбе" тукталышы | "Батырлык мәктәбе" тукталышы | 1 павильон |
| 18 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Фомин урамы (Фомин ур., 8 нче йорт янында) | «Яшел шәһәр» тукталышы | «Яшел шәһәр» тукталышы | Бер-берсенә каршы 2 павильон |
| 19 | Татарстан Республикасы, Менделеевск,Хезмәт урамы («Юбилейный» кибете янында) | "Хезмәт урамы" тукталышы | "Хезмәт урамы" тукталышы | 1 павильон |
| 20 | Татарстан Республикасы, Менделеевск,Хезмәт урамы («Без продавца» кибете янында) | "Хезмәт урамы" тукталышы | "Хезмәт урамы" тукталышы | 1 павильон |
| 21 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Төньяк - Чоловский урамы ( "үзәк район хастаханәсе балалар | «Балалар поликлиникасы» тукталышы | «Балалар поликлиникасы» тукталышы | Бер-берсенә каршы 2 павильон |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | поликлиникасы ягыннан "Чулман" базары янында | | | |
| 22 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Чоловский урамы (шәһәр мунчасы янында) | "Шәһәр мунчасы" тукталышы | "Шәһәр мунчасы" тукталышы | Бер-берсенә каршы 2 павильон |
| 23 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Октябрь урамы (кунакханә янында) | "Кунакханә" тукталышы | "Кунакханә" тукталышы | 1 павильон |
| 24 | Татарстан Республикасы, Менделеевск шәһ., Совет ур., 14А («1 нче гимназия» МББУ янында) | «1 нче гимназия» тукталышы | «1 нче гимназия» тукталышы | 1 павильон |
| 25 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Октябрь урамы (ҮРХ янында) | "ҮРХ" тукталышы | "ҮРХ" тукталышы | 1 павильон |
| 26 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Гассар урамы (3 нче үткәргеч) | "Химзавод" тукталышы | "Химзавод" тукталышы | Бер-берсенә каршы 2 павильон |
| 27 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Гунин урамы | "Гунин урамы" тукталышы | "Гунин урамы" тукталышы | Бер-берсенә каршы 2 павильон |
| 28 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Гунин урамы ("Альбина" кибете янында) | “Урманчылык” тукталышы | «Урманчылык» тукталышы | Бер-берсенә каршы 2 павильон |
| 29 | Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, М-7, Ижауга килү юлы, 15 нче километр (Метелица янында) | "Метелица" тукталышы | "Метелица" тукталышы | 1 павильон |
| 30 | Татарстан Республикасы, Менделеевск (Монай авылы янында) | "Монай" тукталышы | "Монай" тукталышы | 2 павильон |
| 31 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Гунин урамы ("Йолдыз" кибете янында) | "Ленин урамы" тукталышы | "Ленин урамы" тукталышы | 1 павильон |
| 32 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Ленин | "Ушковлар утары" тукталышы | "Ушковлар утары" тукталышы | Бер-берсенә каршы 2 павильон |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | урамы (Ушковлар утары янында) | | | |
| 33 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Гассар урамы | "Ушков утраулары паркы" тукталышы | "Ушков утраулары паркы" тукталышы | Павлильон юк |
| 34 | Татарстан Республикасы, Менделеевск, Габдулла Тукай урамы (Этюд "яшь тамашачы театры янында) | "Этюд" тукталышы | "Этюд" тукталышы | Павлильон юк |